ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕЧЕКУРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН ЧӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

*422483д . село Нижнее Чекурское*
*Телефон: 33-1-34*

*422483, Түбән Чәке авылы*
*телефон: 33-1-34*

с.Нижнее Чекурское

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

**07.06.2018 ел** **№ 13**

Муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентын раслау турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитетының 2011 елның 9 мартындагы 111 номерлы карары белән расланган (2012 елның 28 гыйнварындагы 50 номерлы, 2015 елның 19 маендагы 203 номерлы редакциясендә) "Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә" туры китереп, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Раслраргa:

1.1. Муниципаль милектә булган өслек су объектын яисә аның бер өлешен файдалануга бирү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент
( 1 нче кушымта ).

1.2. Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта);

1.3. Авиация эшләрен башкаруга, парашют сикерүләренә, һава судноларының демонстрацион очышларына, пилотсыз очу аппаратларының очышларына, җирлек территориясе өстеннән бәйләүче аэростатларны күтәрүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта);
1.4. Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең тугрылыгын таныклау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта);
1.5. Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты: васыятьнамәне раслау яки ышанычнамә таныклыгы (5 нче кушымта);
1.6. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта).
2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл жирлеге башлыгының «муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 29.01.2016 ел, №2 карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл жирлеге бүлегендә игълан итәргә.
4. Әлеге карар кабул ителгәннән бирле үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Түбән Чәке авыл җирлеге башлыгы: О.Б.Албутов